**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**"26" октябрь 2022 ел** **№330**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 08 маендагы 99 номерлы «Азнакай муниципаль районы «Административ хуҗалык идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2022 елның 18 февралендәге 37 номерлы карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 02 августындагы 751 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәт хакы шартлары турында» карарын үзгәреш кертү хакында», 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфа окладларын арттыру турында» карарлары нигезендә, карар итә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге ,188-28 номерлы «Бюджет өлкәсендәге эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»карары белән билгеләнгән, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

2. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 08 маендагы 99 номерлы «Азнакай муниципаль районы «Административ хуҗалык идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» карарына (2022 елның 18 февралендәге 37 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.1. 1.6 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Муниципаль учреждение җитәкчесенең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи окладын секретареның вазыйфаи окладын күләменә тапкырлар исәпләп чыгарыла, ул 11 958 сум 00 тиен тәшкил итә.».

2.2. 3.2 пунктының 7) пунктчасының өченче абзацында «7 процент тариф ставкасы» сүзләрен « хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары О.Н. Газизова